# СОВЕТ САКЛОВ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## РЕШЕНИЕ

2 июня 2015г. № 9

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САКЛАУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮЧЕ ЗАТКА ПЕНСИЯГӘ ЧЫГУ УҢАЕННАН БЕР ТАПКЫР БИРЕЛӘ ТОРГАН АКЧАЛАТА БҮЛӘКЛӘҮ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнеӊ вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнеӊ сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнеӊ сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 12.02.2009 елдагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затка пенсиягә чыгу уңаеннан бер тапкыр җбирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе турында нигезләмәне 1 кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенеӊ рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге
Советы рәисе А.Ф.Мухаметгараев

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге Советының
2015 елның 2 июнендәге 9 нчы
номерлы Совет карарына 1 кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САКЛАУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮЧЕ ЗАТКА ПЕНСИЯГӘ ЧЫГУ УҢАЕННАН БЕР ТАПКЫР БИРЕЛӘ ТОРГАН АКЧАЛАТА БҮЛӘКЛӘҮ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Әлеге Нигезләмә «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында»12.02.2009 елдагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең муниципаль вазыйфасын биләүче затка пенсиягә чыгуга (алга таба - бер тапкыр бирелә торган бүләкләү) бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе турында эшләнгән.

2. Муниципаль хезмәттән эштән киткәндә муниципаль вазыйфаны биләүче затка, пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, аның эштән азат ителгән көнгә билгеләнгән сайланма вазыйфасы буенча айлык акчалата кереме 5 ел булганда һәм муниципаль хезмәтнең һәр тулы елы өчен – өстәмә 0,5 әр, ләкин муниципаль вазыйфаны биләп торучы затның акчалата эчтәлеге уннан да артмаган күләмдә түләнә. Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәттән муниципаль вазыйфаны биләп торучы зат эштән азат ителгән көнгә билгеләнә.

3. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү турындагы карар җирле үзидарәнең вәкиллекле органы (муниципаль вазыйфаны биләгән зат) тарафыннан, пенсиягә чыгу сәбәпле, муниципаль вазыйфа биләүче затны эштән азат итү турында җирле үзидарә органы (алга таба – Муниципаль орган) карары кабул ителү белән бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

4. Бер тапкыр бирелә торган бүләк муниципаль вазыйфаны биләп торучы зат муниципаль вазыйфаны биләп торучы зат эштән азат ителгәнче, бер айдан да соңга калмыйча түләнә.

5. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата керем составына кертелә:

айлык акчалата бүләкләү;

вазыйфаи оклад;

тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә.

6. Бер тапкыр бирелә торган Бүләк хезмәт кенәгәсендә бер тапкыр бирелә. Гражданга пенсиягә чыккач һәм аннан соң муниципаль хезмәт туктатылгач, бер тапкыр бирелә торган бүләк кабат түләнми.